ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24 гыйнвар, 2019 ел № 29/5

2018 елда Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча җәмәгать тыңлаулары хакында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 28 маддәсенә, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 19, 28 маддәләренә, Шәһәр Советының 2008 елның 25 сентябрендәге 34/8 санлы Карары белән расланган гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезнамәгә таянып,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. 2018 елда Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрү көнен 2019 елның 11 мартына, үткәрү вакытын 14:00 сәгатькә тәгаенләргә, җәмәгать тыңлауларын үткәрү урыны итеп Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты бинасын (Х.Туфан проспекты, 23 йорт), 400 залны билгеләргә.
2. 2018 елда Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча җәмәгать тыңлауларын үткәрү буенча комиссия составын кушымтада каралганча расларга.
3. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының 29/5 Карарына
кушымта
24 гыйнвар, 2019 ел

2018 елда Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрү комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Сәгыйдуллина Ирина Алексеевна | – комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы; |

комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Хамаева Гөлназ Гарифулла кызы | – Башкарма комитетның финанс идарәсе башлыгы урынбасары, бюджет бүлеге башлыгы; |
| Шакирова Ләйсән Әзһәм кызы | – Башкарма комитетның финанс идарәсе башлыгы урынбасары, бюджет бүлеге башлыгы |
| Галиева Ләйсән Ринат кызы | – Башкарма комитетның финанс идарәсе бюджет сәясәте бүлеге башлыгы; |
| Хәбибрахманова Эльвира Марс кызы | – Башкарма комитетның финанс идарәсе финанс ресурсларын планлаштыру, анализлау һәм прогнозлау бүлеге башлыгы. |